КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 апрель г.Казань № 544

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 14 август, 598 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 сентябрь, 607 нче; 2017 ел, 26 июль, 516 нчы, 2019 ел, 2 сентябрь, 770 нче, 2020 ел, 28 август, 752 нче, 2021 ел, 15 июнь, 458 нче, 2022 ел, 07 июнь, 532 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибенә, 4.1 пунктның алтынчы абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисы турында» 2021 ел, 28 апрель, 289 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 июль, 730 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисы турында нигезләмәдә:

1.3 пунктның бишенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисы составында:

проект офисы составыннан С.А.Вершининны, Т.В.Зайцеваны, М.С.Ротарьне, Р.Р.Сибгатуллинны, Т.Д.Сөләймановны, А.М.Шиһаповны чыгарырга;

проект офисы составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Гыйсмәтов Радик Расыйх улын | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасарын |
| Ильичева Екатерина Владимировнаны | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү һәм эш башкару бүлеге башлыгын |
| Музалевская Алеся Исмәгыйль кызын | Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасарын |
| Мостафина Софья Альфред кызын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасарын |
| Тарнавский Егор Александровичны | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры урынбасарын |
| Шәмсиев Айрат Дөлфәт улын | Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары - Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаменты директорын; |

Сыраева Ләйсән Касыйм кызы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең Мәгълүмат-аналитика идарәсе башлыгын, проект офисы рәистәшен (килешү буенча)»;

Вәлиуллина Асия Зиннәт кызы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары (килешү буенча)»;

Гарипов Илнур Мәхмүт улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасарын –Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгын (килешү буенча)»;

Гаязов Рөстәм Камил улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы урынбасары – Идарәнең коррупциягә каршы мониторинг бүлеге мөдирен (килешү буенча)»;

Глухова Лариса Юрьевна вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгын (килешү буенча)»;

Закиров Фердинат Равил улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары (килешү буенча)»;

Килькеева Роза Рифкат кызы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының цифрлы трансформация программасын раслау турында» 2021 ел, 29 декабрь, 1314 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 24 декабрь, 1414 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының цифрлы трансформация программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлек таблицасында:

41 пунктның 4 графасының 1.2 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

43 пунктның 4 графасының 1.2 пунктчасында «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Аларның барлыкка килүе гражданнарга социаль яклау (ярдәм), социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү чараларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне алу мөмкинлеген бирә торган вакыйгалар белешмәлеген формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында» 2021 елның 26 маендлагы 341н номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Аларның барлыкка килүе гражданнарга социаль яклау (ярдәм), социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү чараларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне алу мөмкинлеген бирә торган вакыйгалар белешмәлеген формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында» 2022 елның 14 гынварындагы 11н номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

46 пунктның 4 графасының 1.2 пунктчасында «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Аларның барлыкка килүе гражданнарга социаль яклау (ярдәм), социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү чараларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне алу мөмкинлеген бирә торган вакыйгалар белешмәлеген формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында» 2021 елның 26 маендлагы 341н номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Аларның барлыкка килүе гражданнарга социаль яклау (ярдәм), социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү чараларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне алу мөмкинлеген бирә торган вакыйгалар белешмәлеген формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында» 2022 елның 14 гынварындагы 11н номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

49 пунктның 4 графасында «РПФ» сүзен «РСФ» сүзенә алмаштырырга, «СИФ» сүзен һәм «СИФ - Россия Федерациясе Социаль иминият фонды» сүзләрен төшереп калдырырга, «РПФ - Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «РСФ - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга;

59 пунктның 4 графасының 6 пунктчасында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 - 2023 уку елына Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларында һөнәри укытуның төп программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм аның күләмнәрен раслау турында» 2021 ел, 25 март, 827 нче карары» сүзләрен «Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге эффективлыгын һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторларын раслау турында» 2022 ел, 23 март, 256 нчы карары» сүзләренә алмаштырырга;

74 пунктта:

4 графаның 3 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ГТХ» күрсәткечен билгеләү өчен статистик белешмәләр Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы юл-транспорт һәлакәтләре турында федераль статистик күзәтүне оештыру өчен аны тутыру күрсәтмәләре белән федераль статистик күзәтү рәвешен раслау турында» 2021 елның 4 июнендәге 305 номерлы боерыгы белән расланган «Юл-транспорт һәлакәтләре турында белешмәләр» юл-транспорт һәлакәтләренең федераль статистик күзәтүе формасының 1 бүлегендәге 2 графаның 1 юлында бар ( РГАФ 3.1 пункты).»;

4 графның 5 пунктчасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 29 июнендәге 647 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 сентябрендәге 1502 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин